**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 22 май № 367

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат ресурсы турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 23 декабрь, 1014 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат ресурсы турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 23 декабрь, 1014 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

2015 елда Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен https://intra.tatar.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәтенең эчке контурындагы «Мәгълүмати статистика ресурсы» автоматлаштырылган системасында яки «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасында Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты урнаштыра торган мәгълүмати материаллар исемлеген;

«Лицензияләү хезмәте сыйфатын бәяләү анкетасы (бер тапкыр тутырыла торган) республика дәүләт статистика күзәтүе формасын.»;

2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле егерменче абзац өстәргә:

«Лицензияләү хезмәте сыйфатын бәяләү анкетасы (бер тапкыр тутырыла торган);»;

карарга кушымта нигезендә «Лицензияләү хезмәте сыйфатын бәяләү анкетасы

(бер тапкыр тутырыла торган) республика дәүләт статистика күзәтүе формасын өстәргә;

әлеге карар белән расланган 2015 елда Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен https://intra.tatar.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәтенең эчке контурындагы «Мәгълүмати статистика ресурсы» автоматлаштырылган системасында яки «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасында Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты урнаштыра торган мәгълүмати материаллар исемлегендә:

6 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 6.5 нче пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «6.5. | «Кара металл, төсле металл ватыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сатуны гамәлгә ашыручы предприятеләргә социологик сораштыру үткәрү» таблица материалы | республика | елга бер тапкыр | 30.10.2015 (2015 ел өчен)». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\367.docx